ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.12.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2471**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 03 августындагы 313 номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 28 декабренә үзгәрешләр белән)» 2017 елның 18 июлендәге 178–ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

2 нче абзацның 1.5 п. «кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә һәм урта предприятиеләргә» сүзләреннән соң «белешмәләре кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән» сүзләрен өстәргә;

3 нче абзацның 6.1 п. «субсидия алучының ризалыгы» сүзләреннән соң «субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин

итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затлар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм иҗтимагый – хокукый оешмалар катнашындагы җәмгыятьләрдән тыш аларның устав (склад) капиталында, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерция оешмаларыннан тыш) » сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В.Старостин